**ГЛАВА**
**Шаршадинского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Шаршады авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.09.2022 Шаршады № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Шаршады торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Шаршады авыл җирлеге башлыгы к а р а р  и т т е :

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Шаршады торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2022 елның 12 октябрендә 14 сәг 00 мин билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Шаршады торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Шаршады авылының Зәйнетдинов урамы өчен вак таш сатып алу һәм җәю.

2.Шаршады урамнарын кардан чистарту.

3. Халыкны су белән тәэмин итү (су белән тәэмин итү өчен тирәнлек насосларын ремонтлау, аларга хезмәт күрсәтү, сатып алу һәм башка эшләр).

4.Хезмәт килешүе буенча янгын сүндерү машинасы йөртүчесенә түләү, янгын сүндерү машинасы өчен ягулык-майлау материаллары алу.

5. Хезмәт килешүе буенча электрик хезмәтенә түләү, урамнарны яктырту өчен яктылык диодлы лампалар алу, урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Шаршады авылы, Урманчылар урамы, авыл клубы янындагы мәйданчык адресы буенча үткәрергә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Шаршады авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Шаршады авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы С.Л.Залетов